**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «30» ноябреннән № 269

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023елның 19 октябрендәге 238 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023елның 19 октябрендәге 238 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктындагы 1.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларын, һәр уку көненә 9 сум 20 тиен күләмендә субсидия һәм ата-аналар түләвен исәпкә ал, 50 сумнан торган кайнар тукландыруны оештырырга;».

1.2. 1 пунктындагы 1.3 пунктчасында «40 сум» сүзләрен «50 сум» сүзләренә алыштырырга.

1.3. 1 пунктындагы 1.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) укучыларны җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлары өчен бәясе 66,76 сумлык и 25 сумлык;

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 25 сумлык һәм 50 сумлык.».

1.4. 1 пунктындагы 1.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Ата-аналары яки законлы вәкилләре махсус хәрби операциядә катнаша торган гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлары өчен бәясе 66,76 сумлык и 25 сумлык;

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 25 сумлык һәм 50 сумлык.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов